**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 1 августындагы 3246 номерлы карары**

**2024 елда бөтенроссия һәм республика олимпиадаларында**
**җиңүчеләрне һәм призлы урын алучыларны бүләкләү турында**

«2022-2026 елларга Казан шәһәрендә мәгарифне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында, интеллектуаль яктан сәләтле һәм талантлы мәктәп укучыларын ачыклау һәм аларга булышлык итү, аларның иҗади сәләтләрен үстерү мөмкинлеген тәэмин итү максатыннан **карар бирәм**:

1. 2024 елга Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең исемле премияләрен билгеләргә:

- 8 нче сыйныф укучылары өчен республика олимпиадасында җиңүчеләргә һәм призлы урын алучыларга (бөтенроссия укучылар олимпиадасының 24 предметы);
- геология, Татарстан тарихы буенча республика олимпиадасында җиңүчеләргә һәм призлы урын алучыларга;
- 7-11 сыйныф укучылары өчен мәктәп укучылары республика олимпиадасында җиңүчеләргә һәм призлы урын алучыларга (туган телдә белем бирә торган мәктәп укучылары өчен татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, көнчыгыш телләр);
- бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының төбәк этабында җиңүчеләргә һәм призлы урын алучыларга;
- бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында җиңүчеләргә һәм призлы урын алучыларга.

2. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә 2024 елда мәктәп укучыларының бөтенроссия һәм республика олимпиадаларында җиңүчеләргә һәм призлы урын алучыларга Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең исемле стипендияләрен билгеләү һәм түләү тәртибен расларга.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (И.А.Ризванов):

3.1. 8 нче сыйныф укучылары өчен республика олимпиадасында җиңүчеләр һәм призлы урын алучылар (бөтенроссия укучылар олимпиадасының

24 предметы), геология, Татарстан тарихы буенча мәктәп укучылары республика олимпиадасында җиңүчеләр һәм призлы урын алучылар, 7-11 сыйныф укучылары өчен республика олимпиадасында җиңүчеләр һәм призлы урын алучылар (туган телдә белем бирә торган мәктәп укучылары өчен татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, көнчыгыш телләр); бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының төбәк этабында һәм йомгаклау этабында җиңүчеләр һәм призлы урын алучылар турында мәгълүматларны гомумиләштерүне тәэмин итәргә;

3.2. укучылар олимпиадаларында җиңүчеләрне һәм призлы урын алучыларны бүләкләүне тәэмин итәргә;

3.3. исемле премияләр түләүгә чыгымнарны 2024 елга Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең бюджет исемлегендә каралган ассигнованиеләр чикләрендә 23 015 000 сум күләмендә, шул исәптән Казан шәһәре бюджеты чараларының ел башына 8 015 000 сум күләмендә калган өлеше хисабына гамәлгә ашырырга.

4. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 1 августындагы
3246 номерлы карарына кушымта

**2024 елда мәктәп укучыларының бөтенроссия һәм республика олимпиадаларында җиңүчеләргә һәм призлы урын алучыларга Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең исемле стипендияләрен билгеләү һәм түләү тәртибе**

1. Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең исемле премияләре (алга таба − премияләр) интеллектуаль яктан сәләтле балаларга булышлык итү һәм аларны бүләкләү, укучыларның сәләтләрен тормышка ашыру мөмкинлекләрен киңәйтү максатыннан булдырыла.

2. Премияләр 8 нче сыйныф укучылары өчен республика олимпиадасында җиңүчеләргә һәм призлы урын алучыларга (бөтенроссия укучылар олимпиадасының 24 предметы), геология, Татарстан тарихы буенча мәктәп укучылары республика олимпиадасында җиңүчеләргә һәм призлы урын алучыларга, 7-11 сыйныф укучылары өчен республика олимпиадасында җиңүчеләргә һәм призлы урын алучыларга (туган телдә белем бирә торган мәктәп укучылары өчен татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, көнчыгыш телләр), бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының төбәк этабында һәм йомгаклау этабында җиңүчеләргә һәм призлы урын алучыларга – Казан шәһәре муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларына, шулай ук «Казан (Идел буе) Федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге лицее» гомуми белем бирү интернат мәктәбендә, Казан (Идел буе) Федераль университетының IT-лицее» гомуми белем бирү интернат мәктәбендә, «Советлар Союзы Герое Б.К.Кузнецов исемендәге Казан шәһәре кадетлар интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә, «Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Казан суворов хәрби училищесы» федераль дәүләт казна гомуми белем бирү учреждениесендә, «Халыкара Казан мәктәбе» автоном коммерцияле булмаган гомуми белем бирү оешмасында, Казан шәһәренең «“Адымнар – белемгә һәм бердәмлеккә юл” полилингваль комплексы» дәүләт автоном гомуми белем бирү оешмасында, «И.В.Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесендә, «Бала-Сити академиясе (Балалар шәһәре)» автоном коммерцияле булмаган гомуми белем бирү оешмасында, «Елена-Сервис» урта

гомуми белем бирү мәктәбе» шәхси гомуми белем бирү учреждениесендә, «Казан милли тикшеренү технология университеты-Казан авиация институтының инженерлык лицей-интернаты» махсуслаштырылган фәнни-өйрәнү үзәгендә, «Казан инновацион университеты көллияте» һөнәри белем бирү учреждениесендә, Казан шәһәренең «Госмания» урта гомуми белем бирү мәктәбе» гомуми белем бирү хосусый учреждениесендә укучыларга 2024 елның августында бирелә.

3. Премияләр шәхси характерда.

Премиянең күләме әлеге Тәртип белән билгеләнә һәм укучының иң югары нәтиҗәсе буенча түбәндәге тәртиптә билгеләнә:

- 8 нче сыйныф укучылары өчен республика олимпиадасы (бөтенроссия укучылар олимпиадасының 24 предметы), геология, Татарстан тарихы буенча мәктәп укучылары республика олимпиадасы, 7-11 сыйныф укучылары өчен республика олимпиадасы (туган телдә белем бирә торган мәктәп укучылары өчен татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, көнчыгыш телләр), бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының төбәк этабында җиңүчеләргә һәм призлы урын алучыларга премия бер призлы урын өчен бирелә һәм призлы урыннар санына бәйле түгел;

- бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында җиңүчеләргә һәм призлы урын алучыларга түләү призлы урыннар саны буенча башкарыла.

Премияләрнең күләмнәре:

- 8 нче сыйныф укучылары өчен республика олимпиадасында җиңүчеләргә һәм призлы урын алучыларга (бөтенроссия укучылар олимпиадасының 24 предметы), геология, Татарстан тарихы буенча мәктәп укучылары республика олимпиадасында җиңүчеләргә һәм призлы урын алучыларга – 5 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

- 7-11 сыйныф укучылары өчен республика олимпиадасында җиңүчеләргә һәм призлы урын алучыларга (туган телдә белем бирә торган мәктәп укучылары өчен татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, көнчыгыш телләр) һәм бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының төбәк этабында җиңүчеләргә һәм призлы урын алучыларга – 20 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

- бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында җиңүчеләргә – 40 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

- бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында призлы урын алучыларга – 30 000 сум (салым түләүләрен дә кертеп);

4. 2024 елның 15 августына кадәр премия алуга дәгъва кылучы укучы укучылар олимпиадасы узган вакытта үзе укыган белем бирү учреждениесенә түбәндәге документларны кулдан тапшыра:

- премия укучының ата-анасының (законлы вәкиленең) исәп-хисап счетына күчерелергә тиеш булган очракта, әлеге Тәртипнең 1 номерлы кушымтасында билгеләнгән форма буенча гариза;

- укучы паспортының яшәү урыны буенча теркәлү турында тамга куелган күчермәсе;

- физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык;

- укучының мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы (СНИЛС) мәгълүматлары;

- укучының (укучының ата-анасының (законлы вәкиленең) Россия кредит оешмасында ачылган, түләү башкарылачак счеты реквизитлары;

- ата-ананың (законлы вәкилнең) һәм (яки) укучының әлеге Тәртипнең 2 номерлы кушымтасында билгеләнгән форма буенча язылган шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы.

Башка документлар тапшыру таләп ителми.

Кирәкле документлар исемлеге турында мәгълүмат Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең (алга таба – Идарә) рәсми порталында (https://obrazovanie.kzn.ru/) әлеге Карарны раслау көненнән башлап 3 эш көне эчендә урнаштырыла.

Әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән белем бирү учреждениеләре әлеге пунктта күрсәтелгән документларны 2024 елның 16 августына кадәр Идарәгә җибәрәләр.

5. Идарә 2024 елның 20 августына кадәр әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документларны: комплектлылыгын, аларда булган мәгълүматның тулылыгын һәм дөреслеген карап тикшерә, шулай ук Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының республика олимпиадасының йомгаклау этабы һәм Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының төбәк этабы йомгаклары турындагы боерыклары, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының Бөтенроссия олимпиадасының йомгаклау этабы нәтиҗәләре турындагы боерыклары нигезендә белем алучыларның казанышларының дөреслеген тикшерә.

Премия алучылар исемлекләренә әлеге Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән документларны тапшырган һәм призлы урын алучылар һәм җиңүчеләр булган затлар кертелә:

- 8 нче сыйныф укучылары өчен республика олимпиадасы (бөтенроссия укучылар олимпиадасының 24 предметы), геология, Татарстан тарихы буенча мәктәп укучылары республика олимпиадасы, 7-11 сыйныф укучылары өчен республика олимпиадасы (туган телдә белем бирә торган мәктәп укучылары өчен татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, көнчыгыш телләр), бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының төбәк этабы нәтиҗәләре буенча – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыклары нигезендә;

- бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабы нәтиҗәләре буенча – Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы әмерләре нигезендә раслана.

2024 елның 1 сентябренә кадәр Идарә башлыгы боерыгы белән премия алучыларның исемлекләре раслана.

6. Премия бирү өчен Идарә әмере нигез булып тора, әлеге әмер белән премия алучыларның исемлекләре раслана.

Премия Идарә тарафыннан боерык басылып чыккан көннән алып 10 эш көне эчендә укучының исәп-хисап счетына яки укучының ата-анасының (законлы вәкиленең) исәп-хисап счетына акча күчерү юлы белән түләнә.

2024 елда мәктәп укучыларының бөтенроссия
һәм республика олимпиадаларында
җиңүчеләргә һәм призлы урын алучыларга
Казан шәһәре Башкарма комитеты
Җитәкчесенең исемле премияләрен билгеләү
һәм түләү тәртибенә
1 номерлы кушымта
(Форма)

«Казан шәһәре Башкарма комитетының
Мәгариф идарәсе» муниципаль казна
учреждениесенең баш бухгалтерына

______________________________________
(Ф.И.А.)

______________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)

______________________________________

______________________________________
(туган көне, шәхесне таныклый торган документның реквизитлары)

______________________________________
(элемтә өчен телефон)

**Гариза**

Укучылар олимпиадасы нәтиҗәләре буенча миңа тиешле премияне түбәндәге реквизитлар буенча әниемнең/этиемнең

______________________________________________________________________*
(атасының/анасының фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)

банк картасына күчерүегезне сорыйм:

исәп-хисап счеты номеры ____________________________________________

банкның атамасы ____________________________________________

БИК ____________________________________________

корреспондент счеты ____________________________________________

Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН): ______________________

КПП ____________________________________________

__________________ __________________
(дата) (имза)

Ата-ананың (законлы вәкилнең) ризалыгы*:

__________________ __________________ __________________ __________
(«каршы түгел») (имза) (имзаның аңлатмасы) (дата)

*Премия ата-ананың (законлы вәкилнең) исәп-хисап счетына күчерелгән очракта.

2024 елда мәктәп укучыларының бөтенроссия һәм республика олимпиадаларында җиңүчеләргә һәм призлы урын алучыларга Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең исемле премияләрен билгеләү һәм түләү тәртибенә 2 номерлы кушымта
(Форма)

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык**

Мин, ______________________________________________________________,
(шәхси мәгълүматлар субъектының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))
түбәндәге адрес буенча теркәлгән: ___________________________________, паспорт сериясе _______ номеры _____________ ________ елның «___» ____________ бирелгән
(бирелү вакыты)
____________________________________________________________________________,
(документны биргән органның атамасы)
2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 9, 10 статьялары нигезендә үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә 2024 елда мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләргә һәм призлы урын алучыларга Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең исемле премиясен алу максатыннан операторга – «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә (420111, Россия, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Большая Красная ур., 1 йорт) автоматлаштырылган, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча минем шәхси мәгълүматларымны җыюга, язуга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, төгәлләштерүгә (яңарту, үзгәртү), аерып алуга, куллануга, тапшыруга (бирү, файдалану мөмкинлеге), шәхси үзенчәлекләрен күрсәтмәүгә, блоклауга, бетерүгә, шәхси мәгълүматларны юкка чыгаруга ризалык бирәм, ә нәкъ менә:

1) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), адресы, паспорт мәгълүматлары;

2) банк счеты реквизитлары;

3) салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН);

4) мәҗбүри пенсия иминияте системасындагы аерым шәхси счетның иминият номеры (СНИЛС).

Шәхси мәгълүматларымны эшкәртү белән бәйле хокукларым һәм бурычларым, шул исәптән, шәхси мәгълүматларым үзгәргән очракта, бу хакта операторга хәбәр итәргә тиешлегем; операторга тиешле язмача гариза юллап, үз ризалыгымны теләсә кайсы вакытта кайтарып алырга хокуклы булуым турында миңа аңлатылды.

Килешү аны имзалаган көненнән гамәлгә керә һәм аны язма рәвештә кайтарып алганчы билгесез вакыт эчендә гамәлдә була.

____________________________________________________________________________
(имза, фамилия һәм инициаллар)

Ризалык бирү көне: 20___ елның «____» ____________

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык***

Мин, ______________________________________________________________________,

(шәхси мәгълүматлар субъектының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

түбәндәге адрес буенча теркәлгән: ____________________________, паспорт сериясе _______ номеры _____________ ________ елның «___» ____________ бирелгән

(бирелү вакыты)

_____________________________________________________________________________

(документны биргән органның атамасы)

__________________________________________________________ законлы вәкиле буларак,

(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме)

2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 9, 10 статьялары нигезендә үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә 2024 елда мәктәп укучылары олимпиадаларында җиңүчеләргә һәм призлы урын алучыларга Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең исемле премиясен алу максатыннан операторга – «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә (420111, Россия, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Большая Красная ур., 1 йорт) автоматлаштырылган, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча минем шәхси мәгълүматларымны, шулай ук баламның шәхси мәгълүматларын җыюга, язуга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, төгәлләштерүгә (яңарту, үзгәртү), аерып алуга, куллануга, тапшыруга (бирү, файдалану мөмкинлеге), шәхси үзенчәлекләрен күрсәтмәүгә, блоклауга, бетерүгә, шәхси мәгълүматларны юкка чыгаруга ризалык бирәм, ә нәкъ менә:

1) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), адресы, паспорт мәгълүматлары;

2) банк счеты реквизитлары;

3) салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН);

4) мәҗбүри пенсия иминияте системасындагы аерым шәхси счетның иминият номеры (СНИЛС).

Шәхси мәгълүматларымны эшкәртү белән бәйле хокукларым һәм бурычларым, шул исәптән, шәхси мәгълүматларым үзгәргән очракта, бу хакта операторга хәбәр итәргә тиешлегем; операторга тиешле язмача гариза юллап, үз ризалыгымны теләсә кайсы вакытта кайтарып алырга хокуклы булуым турында миңа аңлатылды.

Килешү аны имзалаган көненнән гамәлгә керә һәм аны язма рәвештә кайтарып алганчы билгесез вакыт эчендә гамәлдә була.

_____________________________________________________________

(имза, фамилия һәм инициаллар)

Ризалык бирү көне: 20___ елның «____» ____________

*Балигъ булмаган баланың ата-анасы тутыра.